ПРОЕКТ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «__» июленнән № ____

2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьясы, «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы иҗтимагый торак комиссиясе нигезләмәсен һәм составын раслау турында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 14 февралендәге 49 номерлы карары, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының 2025 елның 07 февралендәге 56 номерлы хаты нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Гражданнарны азкеремле дип тану турында карар кабул итү өчен, Керемнең чик күрсәткечләрен билгеләүне исәпләү нигезендә 2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керем һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы күләмнәренең иң чик күрсәткечләрен әлеге карарга кушымта нигезендә билгеләргә.

1.1. гаилә әгъзалары (ялгыз яшәүче граждан) милкендәге һәм салым салынырга тиешле милек хакының иң чик күләме:

1.1.1 ялгыз яшәүче граждан өчен - 783 846 сум;

1.1.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 1 567 692 сум;

1.1.3. өч кешедән торган гаилә өчен – 2 351 538 сум;

1.1.4. дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3 135 384 сум;

1.1.5. биш  кешедән торган гаилә өчен - 3 919 230 сум;

1.1.6. алты кешедән торган гаилә өчен - 4 703 076 сум;

1.1.7. җиде кешедән торган гаилә өчен – 5 486 922 сум;

1.1.8. сигез кешедән торган гаилә өчен - 6 270 768 сум;

1.2. гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керем күләме:

1.2.1. ялгыз яшәүче гражданин өчен - 38 811 сум;

1.2.2. ике кешедән торган гаилә өчен – 38 811 сум;

1.2.3. өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – 38 811 сум.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы Иҗтимагый торак комиссиясенә социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип тану максатларында гаиләнең яисә ялгыз яшәүче гражданның керемен исәпләгәндә әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктчаларына таянып эш итәргә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https:/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (инфраструктур үсеш буенча) йөкләргә.

Җитәкче                                                                                                    Е.А. Тарнавский

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «__» июленнән
___ номерлы карарына
кушымта

2025 елга гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының иң чик күләмнәрен исәпләү

1. СЖ = НП х РС х РПС, биредә

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының чиге;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РПС - торак урын мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хисап бәясе – 43 547 сум. «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» коммерциягә карамаган партнерлыгының 2025 елның 07 февралендәге 56 номерлы хатындагы уртача күрсәткеч кулланылды.

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

СЖ = 18 х 1 х 43547 = 783 846 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 2 х 43547 = 1 567 692 сум

в) өч кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 3 х 43547 = 2 351 538 сум

г) дүрт кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 4 х 43547 = 3 135 384 сум

д) биш кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 5 х 43547 = 3 919 230 сум

е) алты кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 6 х 43547 = 4 703 076 сум

ж) җиде кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 х 7 х 43547 = 5 486 922 сум

д) сигез кешедән торган гаиләгә:

СЖ = 18 x 8 x 43547 = 6 270 768 сум

2. Гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең иң чик күләме

ПД =0,7 х СЖ х ПС/(1-(1 + ПС)-КП)/(0,3 х РС), биредә

СЖ - социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны бирү нормасы буенча торак урыны алу өчен базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер айда кредит буенча процент ставкасы (елына 25 % яки беренче кертем 20 % шарты белән аена 25 %) - 0,02;

КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны) (20 ел яисә 240 ай кредит бирү срогы «Татарстан Республикасы ипотека агентлыгы» АҖ мәгълүматы нигезендә);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы белән фатир бәясенең чагыштырмасы;

0,3 - кредит буенча түләүнең гаиләнең айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы;

а) ялгыз яшәүче граждан өчен:

ПД = 0,7 х 783846 х 0,02/ (1- (1 + 0,02)-240)/(0,3 х 1) = 30956,25 сум

б) ике кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 х 1567692 х 0,02/ (1-(1 + 0,02)-240)/(0,3 х 2) = 30956,25 сум

в) өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаиләгә:

ПД = 0,7 х 2351538 х 0,02/ (1-(1 + 0,02)-240)/(0,3 х 3) = 30956,25 сум